ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1; 2013, № 5, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемдә “аларны дәвалау,” сүзләреннән соң “хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,” сүзләрен өстәргә;

2) преамбулада “аларны дәвалау,” сүзләреннән соң “хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,” сүзләрен өстәргә;

3) 1 статьяның 1 өлешендәге беренче абзацта “аларны дәвалау,” сүзләреннән соң “хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,” сүзләрен өстәргә;

4) 5 статьяның 2 өлешендә “аларны дәвалау,” сүзләреннән соң “хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,” сүзләрен өстәргә;

5) кушымтада:

а)

“Муниципаль районнарның һәм шәһәр
округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар
чирләрен кисәтү һәм бетерү,
аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен
уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын
үткәрүне оештыру өлкәсендә
Татарстан Республикасының
аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”
Татарстан Республикасы Законына
кушымта”

сүзләрен

“Муниципаль районнарның һәм шәһәр
округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар
чирләрен кисәтү һәм бетерү,
аларны дәвалау, хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,
кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау
чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә
Татарстан Республикасының
аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”
Татарстан Республикасы Законына
кушымта”

сүзләренә алмаштырырга;

б) исемдә “аларны дәвалау,” сүзләреннән соң “хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,” сүзләрен өстәргә;

в) 2 пунктта “аларны дәвалау,” сүзләреннән соң “хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау,” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 1 июле
№ 48-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ